Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенә кергән Яңа Мокшино, Яңа Баланда авыллары гражданнарының 2020 елда үзара салым кертү турындагы

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның “18” ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлегенә кергән Яңа Мокшино, Яңа Баланда авыллары гражданнары җыены карар итте:

1. Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешегә 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге урамнарны кышкы тәртиптә тоту.

- Ленин урамы, Яңа Баланда авылы, Киров, Гагарин урамы урамнарын ремонтлау (грунт күтәрү, ком һәм вак таш салу);

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Яңа Мокшино авылында урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- Яңа Баланда авылындагы зиратка алачык төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

3. Әлеге карарны Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru (http://pravo.tatarstan.ru).

Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Айдова.